ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д. 52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле
авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.


# КАРАР

**09 декабрь 2024 ел** **№ 34**

**Арча муниципаль районы
"Иске Чүриле авыл җирлеге"
муниципаль берәмлегендә
гражданнардан үзара салым
акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 04 августындагы 49 номерлы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары нигезендә, 13.11. 2024 N 8, 13.11. 2024 N 9, 13.11.2024 N 10, 15.11.2024 N 11, 15.11.2024 N 12, 20.11.2024 N 13, 22.11.2024 № 14 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2023 елның 14 декабрендәге 26 номерлы Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 й., Татарстан Республикасы, Арча районы, Венета авылы,

Школьная урамы, 3 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомольская урамы, 4А йорт, Татарстан Республикасы, Арча районы, Штерә авылы, Совет урамы, 30б йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ Р.Р. Рамазанов

Иске Чүриле авыл җирлеге
башкарма комитетының
09.12.2024 ел, № 34
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2025 елның 17 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә белем алучы студентлар,

б) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен,

в) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар,

түләүләр күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын

раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгәндә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Иске Чүриле авыл җирлеге
башкарма комитетының
09.12.2024 ел, № 34
карарына 2 нче кушымта

Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N _______________

Түләүченең Ф.И.А.и__________________________________________________

Адресы:_______________________________________________________________

Нигезе__________________________________________________________

Сезгә ______________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү___________________________ суммада _____________ сум түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:____________________________________

алучының банкы БИК ____________________________

Сч. N _______________________________________

Алучы Сч. N _______________________________

ИНН ___________________________________________

КПП ___________________________________________

КБК _________________ОКАТО ___________________

Түләүнең билгеләнеше __________________________________________

Җитәкче _________________ _________________________________________

М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Иске Чүриле авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__

суммада _________________ сум

Түләүченең Ф. и.а.и. ________________________________________

Адресы: ______________________________________________

Алдым "___"________ 20__ ел ___________________________

(түләүченең имзасы /ФИАи)

Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек тамыр тутырыла һәм Иске Чүриле авыл җирлеге Башкарма комитетында кала